СОВЕТ РОМОДАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
РОМОДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с. Ромодан

01.11.2022 № 31

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль Районы «Ромодан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру һәм күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасының «Алексеевск муниципаль районы»муниципаль берәмлегенә тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Ромодан авыл җирлеге Уставы нигезендә,

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге Советы**

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының « Ромодан авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру һәм Ромодан авыл җирлегендә күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен тапшырырга.

2. Ромодан авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән Ромодан авыл җирлеге территориясының төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне тормышка ашыру һәм күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзергә (кушымта) тәкъдим итәргә.

3.Вәкаләтләрне тапшыру ел саен Ромодан авыл җирлеге бюджетыннан Алексеевск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

4.Әлеге карарны әлеге вәкаләтләрне кабул итү турында карар чыгару өчен Алексеевск муниципаль районының Алексеевск район Советына җибәрергә.

5. Әлеге карар Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында https://alekseevskiy.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**ТР Алексеевск муниципаль районыРомодан авыл җирлеге Башлыгы, Совет Рәисе** **И.А.Чекалина**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА р05-11124/13 СОВЕТ РОМОДАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ